| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** — **БОЕРЫК**

09.04.2018 г.Казань № 79/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында» 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында» 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгына (22.05.2017 № 117/2-пр, 25.10.2017 № 240/2-пр, 13.03.2018 № 49/2-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык белән расланган «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында:

4.3 пунктның бишенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә грантның иң зур күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланды;

Боерык белән расланган Крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

3.1.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.16. Үз инициативасы белән салым органыннан КФХның Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган белешмә (форма: КНД буенча Код 1120101), иминиятләштерелгән затның – КФХ башлыгының индивидуаль шәхси счетының торышы турында мәгълүмат (форма: СЗИ – 6). Бу документлар КФХның үз инициативасы белән бирелмәгән очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала;»;

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.1.19 пункт өстәргә:

«3.1.19. КФХ башлыгының хезмәт кенәгәсе күчермәсен (булса);»;

5.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән документлар пакетын тулысынча тапшырмаган очракта, конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүченең заявкасын очрашып сөйләшү барышында кире кага.».

таблицада 5.9 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3 | Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җир кишәрлеге булу** | милектә, түләүсез файдалануда | 3 |
| | | 5,5 елдан кимрәк булмаган озак сроклы арендада | 2» |

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» программасына кертелгән үзгәрешләр турында крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына мәгълүмат бирергә.

3. Әлеге Боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбипка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары - министр М.Г. Әхмәтов